Мәгариф идарәсенең боерыгы белән расланды

( № 227-ОД 23нче март)

**Әгерҗе районы яшь каләм осталарының**
**XVIII "Көмеш каләм" район фестиваленең нигезләмәсе**

1. **Гомуми мәгълүмат**

1.1. XVIII "Көмеш каләм" район фестивале 2021 нче ел "Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы", Г.Тукайга 135 ел тулу һәм Иж – Бубый мәдрәсәсенең 240 еллыгы, Габдулла Бубига 150 ел, Гобәйдулла Бубига 155 ел тулу уңаеннан оештырыла.

2. **Фестивальнең бурычлары һәм максатлары:**

- татар теленә, татар әдәбиятына, милли мәдәниятебезгә, халкыбызның гореф-гадәтләренә, рухи байлыгыбызга, тарихыбызга мәхәббәт хисе тәрбияләү;
- туган як тарихын, мәдәниятен өйрәнү, җирле язучылар иҗаты белән кызыксыну;
- укучыларның иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү, аларда иҗади һөнәрләргә карата кызыксыну уяту;
- яшь иҗатчыларны барлау.

1. **Фестивальнең темасы**:

**Кем ярата туган телен,**
**Ярата туган илен (Вәзыйх Рәхимов)**

**Фестивальнең номинацияләре:**
- "Яшь хикәяче" (5-8, 9-11 сыйныф укучылары),
- "Яшь хәбәрче" (5-8, 9-11 сыйныф укучылары) ,
- "Яшь шагыйрь" (5-8, 9-11 сыйныф укучылары),
-"Яшь рәссам" (5-8, 9-11 сыйныф укучылары),
- "Видеоролик" (укучылар, укытучылар катнашында).

"Яшь хикәяче", "Яшь шагыйрь", "Яшь хәбәрче", "Видеоролик" номинацияләре өчен уртак тема– **фестивальнең гомуми темасы.**

• бәйге тематикасына туры килүе;
• иҗади караш.

***"Видеоролик***" номинациясе 3-5 минутны эченә ала. Бирелгән номинациягә таләпләр:

1) сюжетның темага туры килүе (туган телне үстерү, саклау буенча мәктәптә нинди эш башкаралар: сәләтле укучылар белән эш; түгәрәкләр эшчәнлеге; конкурсларда, чараларда катнашу һ.б);
2) оригиналь булуы;
3) информациягә бай булуы;
4) практик кулланылышы;
5) эстетик бизәлеше;

6) регламентның сакланышы.

**-“Яшь рәссам” номинациясе** “Тукай әсәрләре – безнең рәсемнәрдә” темасы буенча үтәчәк. (5-8, 9-11сыйныф укучылары).

Яшь бүленеше:

— 5-8 класслар;

— 9-11 класслар

Эшләр бәйгенең тематикасына туры килергә тиеш. Бәйге өчен кирәкле әсбапларны (карандаш, гуашь, акварель, май, графика һ. б.) алып килергә.. Эшләр А4 форматында башкарыла.

**4. Фестивальдә катнашучылар**

Татар һәм рус мәктәпләрендә укучы татар балалары (5-11 сыйныф укучылары), туган тел (татар теле) укытучылары.

**5. Фестивальне үткәрү шартлары һәм тәртибе**

5.1. Фестиваль 2021 нче елның 22 нче апрелендә Ләбиб Айтуганов исемендәге Девәтернә төп гомумбелем бирү мәктәбендә үткәрелә. Башлану вакыты- сәгать 8.30.

5.2. Фестиваль туган (татар) телдә үткәрелә.

5.3.Фестивальдә нигезләмә шартлары буенча билгеләнгән вакытка кадәр гариза ( кушымта) җибәргән, Әгерҗе районы урта белем бирү оешмаларында белем алучы 4-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Гаризаларны 2021 нче елның 12нче апреленә кадәр Девәтернә төп гомумбелем бирү мәктәбе (raisa-farrakhova@yandex.ru) адресына җибәрергә. Һәр номинациягә мәктәп саен 1 әр укучы һәм 1 җитәкче чакырыла.

5.4. Бәяләү критерийлары:

- язылган чәчмә яки тезмә әсәрнең композицион бөтенлеге, эзлеклелеге,
- төгәллек һәм сөйләм матурлыгы,
- темадан читләшмәве,
- авторның образлы фикерләү осталыгы һәм сурәтләү чараларын куллану үзенчәлеге,

5.5 Фестивальдә катнашучы укучыларга мәгариф идарәсенең сертификатлары, җиңүчеләргә I, II, III дәрәҗәдәге дипломнары тапшырыла.

5.6 Элемтә өчен телефон номерлары:

3-54-31 – Девәтернә төп гомумбелем бирү мәктәбе, 89061172457 – Даутова Альфинур Файзулловна,

89093108785 – Шәйхетдинова Миләүшә Рәшит кызы (милли мәгариф буенча методист).

**Гариза (укучылар өчен)**

| Белем бирү оешма-сының тулы исеме | Катнашучы укучының исеме, фамилиясе | сыйныф | Җитәкчесе | Секция исеме | Яше |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |